ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2.1 пункты, шулай ук әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.1, 9.2 һәм 9.11 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Н.И. Морозова шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында**

Казан шәһәре 2020 елның 21 гыйнвары

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында гражданка Н.И. Морозова шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында судья Ф.Р. Волкова мәгълүматын тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Н.И. Морозова «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2.1 пункты, шулай ук әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның

кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.1, 9.2 һәм 9.11 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

«"Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан 2019 елның 10 декабрендә 1131 номерлы карар кабул ителүгә бәйле рәвештә, аның нигезендә дәгъва белдерелә торган Нигезләмәнең 9.11 пункты яңа редакциядә бәян ителгән иде, 2019 елның 18 декабрендә мөрәҗәгать итүчедән шикаятькә өстәмә килде.

Ләкин 2020 елның 14 гыйнварында гражданка Н.И. Морозова Татарстан Республикасы Конституция судына үз шикаятен кире алу һәм аның буенча эшне туктату турында гариза белән мөрәҗәгать итте.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 47 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына бирелгән мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эшне карый башлаганчы ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан кире алынырга мөмкин. Мөрәҗәгать кире алынган очракта эшне карау туктатыла.

Мөрәҗәгать итүче үз шикаятен Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эшне карый башлаганчы кире алганга күрә, әлеге шикаять буенча эш башкару туктатылырга тиеш.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 47, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм бишенче өлешләренә, 72 статьясына һәм 73 статьясындагы беренче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2.1 пункты, шулай ук әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.1, 9.2 һәм 9.11 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Н.И. Морозова шикаяте буенча эш башкаруны, мөрәҗәгать итүченең әлеге шикаятьне кире алуы сәбәпле, туктатырга.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Н.И. Морозовага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

**№ 1-О**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**